ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

03.10.2025 г. Казань № 243-10/т-2025

Чаллы шәһәренең «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә 2026 елга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 01.10.2025 ел, №18-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чаллы шәһәренең «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә, әлеге карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик максималь тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В.Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.10.2025 № 243-10/т-2025
карарына кушымта

Чаллы шәһәренең «Промжелдортранс-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланууда булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик дәрәҗә максималь тарифлар

I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| Т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Иң чик максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Сидоров маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 11,61 |
| 2. | Автозавод маневр районы буенча 1 км ераклыкка тонналап йөк ташу | 1 тонна | 13,88 |
| 3. | Камаз маневр районы буенча 1 км ераклык өчен тонналап йөк ташу | 1 тонна | 12,89 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» дигән I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге